КИЛӘЧӘК ӨЧЕН КЕРТЕМ
«Танеко»да яңа җитештерү җайланмалары эшли башлады
> 2

ФИДАКАРЬЛЕК ҮРНӘГЕ
Фәрит Мөхәммәтшин «Безнең заман геройлары»н бүләкләде
> 2

ЕЛ СТУДЕНТЫ – 2021
Россиянең иң көчле студенты Казанда укый
> 3

«ТАТНЕФТЬ» УРМАННАРЫ
Компания Татарстанда миллионлаган агач утырта
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 186 (28768) | Сишәмбе | 21 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Яшәеш

Түшәктәге кешене бары тик ярату гына терелтә ала! Күп тә кирәкми үзләренә – кайчак бер җылы сүз җитә. Аларны бары тик өмет яшәтә. Кемнәрдер картлыгында урынга калса, йөгереп йөргән җирдән дә авыруга әйләнүчеләр бар. Андыйларның кайберләрен баласы тәрбияләсә, күпләр якыннарын карар өчен кеше яллый. «ВТ» хәбәрчесе сиделкалар әзерләүче оешма белән элемтәгә керде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

УТЫР ӘЛЕ ЯНЫМА...

Сиделкаларны, министрлык белән килешү төзеп, дәүләтнеке булмаган ике оешма әзерли. Шуның берсе – «Помощник» дип аталган социаль хезмәт күрсәтүче оешма 12 ел инде Мәскәүдә яшәүче өлкәннәргә хезмәт күрсәтә. Бер ел элек алар Татарстанга килгәннәр.

– Казанда сиделка хезмәте 2020 елның мартыннан гына эшли башлады. Оешмабыз Мәскәүнеке булса да, Татарстан буйлап хезмәт күрсәтәбез. Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән бергә эшлибез. Безнең хезмәткәрләр Казанда һәм республиканың барлык районнарында эшли, – ди куратор Рамилә Закирҗанова. – Элек бит мондый мөмкинлек юк иде. Авыл җирендә яшәүчеләрне туганнары, күршеләре ялгыз калдырмаса да, урынга калсалар, барыбер караучы кирәк.

Әби-бабайларны карау өчен хезмәткәрләрне ничек эзлиләр? Без бу хакта да сораштык. Рамилә Закирҗанова әйтүенчә, сиделкаларны игълан аша табалар.

– Үзебезгә чакырып, алар белән сөйләшәбез. Иң элек хөкем ителмәгәнлеге турында белешмә сорыйбыз, аннан соң эш тәҗрибәсен белешәбез. Медицина белеме булган кешеләрне бик теләп кабул итәбез. Эшкә киләм, диючеләрнең табиб күзәтүе үткәнлеге бик мөһим. 2020 елда Мәскәү белгечләре Казанга килеп белем бирә иде. Пандемия башлангач, бар да дистанцион рәвештә генә узды, – ди куратор.

Рамилә Закирҗанова, бу эштә сабырлык, түземлек бик кирәк, дип искәртә. Сиделка хезмәтенә мохтаҗ кешеләр исемлеген социаль яклау һәм комплекслы ярдәм күрсәтү оешмалары төзи икән.

– Хезмәткәрләрне күбрәк ярдәмгә мохтаҗ кеше яшәгән авыл, районнан табабыз. Без күрсәткән хезмәт алар өчен бушлай. Караучыларга акчаны хөкүмәт түли. Алар ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә көненә 4 сәгать булыша. Үзләре теләсә, бу сәгатьләрне арттырып та була. Әмма ул чакта аның өчен кеше үзе түләячәк, – ди Рамилә ханым.

Сиделкалар урында ятып кына торучы кешеләргә дә, аякта йөреп торучыларына да ярдәм итә. Рамилә Закирҗанова сөйләвенчә, бездә күбрәк өлкәннәрне үз якыннары карый икән. Дәүләт тәкъдим иткән хезмәтне әти-әнисен, әби-бабасын калдырып, каядыр барып киләсе кешеләр сайлый. Араларында, сиделка яллап, эшләп тә кайтучылар бар икән.

– Мәскәү белән чагыштырганда бездә әлегә түләүле хезмәт артык киң таралмаган дип саныйм. Өлкәннәр үзләре дә чит кеше карауны кабул итми кайчак. Әмма бер ияләнсәләр, аларны караучылардан аерып та булмый. Өлкәннәргә сиделка билгеләгәнче, без алар белән сөйләшәбез. «Нинди кеше кирәк?» – дип сорыйбыз. Милләтен, яшен дә белешәбез. Без тәкъдим иткәнне ошатучылар да, кире боручылар да бар. Төрле кешедә төрле холык. Кайбер чакта олылар белән уртак тел тапмыйча эштән китүчеләр дә бар, – ди ул.

Рамилә ханым, сиделка булыр өчен тәмле телеңне кызганмаска кирәк, ди.

– Бары тик сөйләшү аша гына бер-береңне аңлап була. Авыру кешене карау җиңел түгел. Урында ятучыларны дөрес итеп әйләндерү, утырту, аларга төрле күнекмәләр ясата белү дә шарт. Сиделка хезмәтенә мохтаҗлар арасында акыл ягыннан зәгыйфь, хәтерен югалткан кешеләр дә бар. Алар белән эшләү аеруча сабырлык сорый, – ди ул.

Сиделка нинди эшләр башкара? Ул ашарга әзерләргә, өлкән кешене ашатырга, аяк-кулларындагы тырнакны кисәргә, чәчен тарарга, тешен чистартырга, урында гына гәүдәләрен юеш чүпрәк белән сөртеп алырга тиеш. Шулай ук кече һәм зур йомышларын үтәтү, урын-җирен алыштыру, хәрәкәтләндерү, төрле якка әйләндерү дә сиделкага йөкләнә. Табиб кушкан даруларын вакытында бирергә, хәлен сорап, кәефен белеп, температурасын, кан басымын үлчәп тә торырга кирәк. Өлкәннәр белән газета-журналлар уку, вак моториканы үстерү буенча ниндидер шөгыль табу да хуплана.

Дәүләт тарафыннан күрсәтелә торган сиделка хезмәте өчен, караучы аена бер кеше тәрбияләсә, 14 мең сум акча түләнә. Үзең яллаган очракта авыруның хәленә карап түләнә. Кемдер гел ятып кына торырга, кайберәүләр үз аягында йөрергә мөмкин. Татарстанда бу хезмәт өчен сәгатенә 100 сумнан 300 сумга кадәр түлиләр. Агентлык аша эшкә урнашканда тәүлегенә 800–1200 сумга кадәр акча бирергә мөмкиннәр. Бездә өлкәннәрне атнага 6 көн караган өчен аена 30–45 мең сумга кадәр акча сорыйлар. Чит илләрдә сиделка хезмәте киң таралган. Германиядә авыру караган өчен аена 1000–1500, Италиядә –1000, Польшада 800 евро түлиләр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Авыруның тормышын яхшырта торган 10 кирәк-ярак

1. Ашату өчен махсус чималдан ясалган, кулдан төшеп китми торган савыт-сабалар.
2. Кресло-коляска.
3. Тотынып йөрү өчен роллатор яки ходункилар.
4. Урыннан торганда тотыну өчен бау.
5. Авыру өчен махсус карават.
6. Терәлеп утыру өчен мендәр.
7. Тәненә яра ясатмый торган матрас.
8. Караватөстенә куеп ашату өчен махсус өстәл.
9. Душ өчен – урындык, ванна өчен – утыргыч.
10. Урындык рәвешендәге бәдрәф.

САН

- Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада сиделка хезмәте «Демография» илкүләм проекты кысасында «Өлкән буын» проекты буенча күрсәтелә.
- 2019 елда 7 районда – 193 кешегә, 2020 елда тагын 13 районда 775 кешегә сиделка хезмәте күрсәтелә башлый. 2021 елның 11 аенда 454 кешегә бу хезмәт күрсәтелгән.
- Сиделка булыр өчен укырга теләүчеләрнең күбесе авыру кешенең якыннары икән. 2019 елда «Тәрбия мәктәбе» («Школа ухода») аша 234 кеше узса, 2020 елда – 1791, 2021 елда 1984 кеше караучы булып эшләр өчен укып чыккан.

Халыкка уңайлы булыр

Киләсе елдан «Дәүләт хезмәтләре» порталында сервислар исемлеге ишәячәк. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин порталда гади халык һәм бизнес өчен тагын 100дән артыграк төбәк сервисы пәйда булачак дип белдерде. Мәсәлән, балаларга кайбер пособиеләр рәсмиләштерү, автомобильләргә техник карау уздыру, салым декларацияләре тапшыру һәм күчемсез милеккә хокукларны түләү шуның аша хәл ителәчәк. Бу җәһәттән тиешле карар имзаланган да инде. Мишустин әйтүенчә, төбәкләр үзләре укытучыларны аттестацияләү, социаль хезмәтләр күрсәтүгә гаризалар тапшыру, бушлай торак бирү кебек өстәмә сервислар урнаштырырга мөмкин. Моңа кадәр «Дәүләт хезмәтләре» порталында электрон мәҗбүри медицина иминияте полисы пәйда булачагы турында хәбәр ителде. Ул штрих-код рәвешендә эшләнелә.

Көпчәкләр «тышаулана»

Казан парковкаларында машиналарының дәүләт номерын яшереп калдыручыларга каршы чара уйлап табылган. Андый машина көпчәкләренә блокираторлар урнаштыра башлаячаклар. Блокираторларны алу өчен элемтә үзәгенә шалтыратырга туры киләчәк: телефон номеры җайланмада күрсәтеләчәк. Белгечләр тиз арада килеп җитәр, дип вәгъдә ителә. Анысы шулай, тик урын алып торган, аңа вакытында түләмәгән өчен саллы гына штраф түләргә туры киләчәк. «Бу яңалык автомобильчеләр арасында тиз таралыр дип уйлыйм. Чәршәмбедән шулай эшли башлыйбыз. Кагыйдәләр барыбыз өчен дә бер төрле. Юлдагы башбаштаклыктан котылып, зур эш башкардык. Аңа кире кайту булмаячак», – диде Казан мэры Илсур Метшин.

Суыта

Бу атнада Татарстанда кисәк суыта. Инде чәршәмбе көнне үк һава температурасы көндез -12-17 градус булачак. Ә инде төнлә һәм иртәнге сәгатьләрдә -22 градуска кадәр суытачак. Урыны белән аз гына кар көтелә. Пәнҗешәмбе көнне республикада төнлә -17 -22 градуска кадәр суыта. Кайбер урыннарда төнлә һәм иртән -27 градуска кадәр суык фаразлана. Җомга көнне суык һава саклана. Урыны белән аз гына кар, көндез һава температурасы -15, -20, төнлә -20, -25 градус чикләрендә тирбәләчәк. Шимбә көнне көндез һәм иртән берникадәр җылытып, температура -9-14 градус булачак, төнлә -17-22 градуска кадәр суытачак. Кар-буран һәм көчле җил көтелә.

COVID-19

Чир ял да итми, китми дә

Россиядә биш атна дәвамында коронавирус инфекциясе йоктырып авыручылар саны кимү күзәтелә. Үлем-китем күрсәткечләре белән дә шулай ук. Уртача алганда, коронавирус бер тәүлеккә 1132 кеше гомерен өзә. Бу декабрь башындагы саннардан берничә дистәгә азрак.

Моңа карап кына ил төбәкләренең барысы да коронавируслы чикләүләрдән баш тартырга ашыкмый. Әмма, сагаеп кына, аз дәрәҗәдә булса да, вазгыятькә бәйле рәвештә кайбер чикләүләр «йомшара».

Шулай да «омикрон» куркыта. Россия дә аның белән очрашмыйча калмаячак. Бер атна эчендә коронавирусның яңа штаммын йоктыручылар саны 25 кешегә җитте. Әлегә үлүчеләр юк.

Узган атна ахырында Россия вице-премьеры Татьяна Голикова илнең дүрт төбәге тиздән күмәк иммунитет күрсәткеченә ирешәчәк дип белдерде. Болар – Чукотка автономияле округы, Карелия, Санкт-Петербург һәм Мәскәү өлкәсе. Аларда коронавируска каршы күмәк иммунитет күрсәткече 75 проценттан артыграк.

– Тыва, Мәскәү, Мурманск, Калининград, Липецк өлкәләре дә калышмый. Аларда бу күрсәткеч 71 проценттан күбрәк, – диде Татьяна Голикова. Сүз уңаеннан, Россиядә күмәк иммунитет булдырган бердәнбер төбәк булып Севастополь санала. Анда халыкның 88,7 проценты коронавируска каршы вакцина ясаткан.

Татарстанда да коронавирус белән чирләүчеләр саны сизелерлек дәрәҗәдә кимеде. Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов «шимбә киңәшмәсе» вакытында белдергәнчә, бу – катгый чараларның нәтиҗәсе.

– Чирнең һәр яңа «дулкын»ы безнең алдыбызга яңа бурычлар куя һәм вазгыятьне кулдан ычкындырмас өчен күбрәк көч таләп итә. Системалы эшне дәвам итәргә кирәк. Вакцина ясатуны да киметмәскә. Республикада 500 меңнән артык доза бар, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Мәгълүм булганча, Татарстан кафе-рестораннарына 20 декабрьдән башлап 10 гыйнварга кадәр төнге 1гә кадәр эшләргә рөхсәт ителде. 31 декабрьдә исә иртәнге 3кә кадәр хезмәт күрсәтергә ярый.

– Без үз өстебезгә бик җитди җаваплылык алабыз, бик күп әзерлек эшләре башкарылды, – диде бу уңайдан Президент.

САН

- Татарстанда 2260399 кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан. Бер тәүлеккә үсеш – 3002 кеше. Вакцина ясатучыларның 1859124е прививканың икенче дозасын кадаткан.
- Россиядә COVID-19 инфекциясе таралуның иң югары күрсәткече Түбән Новгород өлкәсендә һәм Мәскәүдә теркәлгән (1,12). Ил күләмендә бу сан – 0,96.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Талия МИҢНУЛЛИНА, Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе:

Без Татарстанны белсеннәр, күрсеннәр өчен ни өчен күп чыгымнар тотабызмы? Чөнки белмиләр икән, бирегә инвестиция кертүче дә булмаячак. Бу очракта туризмны җәелдерү бик уңайлы булыр иде дә, ни кызганыч, кредит бирүчеләр туризм өлкәсенә акча салырга бик ашкынып тормыйлар шул.

(«Реальное время» электрон басмасына әңгәмәсеннән)

ЯҢА ЕЛ ТЕЛӘКЛӘРЕ

«Работа.ру» хезмәте Россиядә яшәүчеләрдән: «Яңа ел төнендә нинди теләк теләячәксез?» – дип сорашкан. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, күпчелек матди хәленең яхшыруын, сәламәтлек һәм ил-көнгә тынычлык теләргә җыена.

Яхшы хезмәт хакы	34%
Бәхет	33%
Коронавирус пандемиясенең бетүе	24%
Яңа машина (фатир/дача)	20%
Сәяхәткә чыгу	14%
Сөйгән ярын табу	13%
Социаль челтәрләрдә күп язылучылар	4%

«КАМАЗ-Мастер» яңа машинада ярышачак

Чаллының «КАМАЗ-Мастер» командасы «Дакар» ралли-марафонында катнашу өчен 26 декабрьдә Согуд Гарәбстанына китәчәк. Быелгы ярыш 2 гыйнварда башланып, 14ендә тәмамлана. Ул инде өченче мәртәбә шушы илдә уза.

Чаллы командасы раллида дүрт экипаж белән чыгыш ясый. Шуның икесе яңа машиналарда ярышачак. Алар белән «Дакар»ның гамәлдәге җиңүчесе Дмитрий Сотников һәм раллины биш мәртәбә откан Эдуард Николаев идарә итәчәк. «Быелгы «Дакар»да төп бурычларның берсе – машиналарның яңа модельләрен күрсәтү. Завод, республика, ил җитәкчелегенең, тамашачының, хезмәттәшләрнең бездән ни көткәнен беләбез. Россия халкын ел башында ук уңышлы чыгыш белән сөендерәсе килә. Моның өчен барысын да эшләячәкбез», – диде команда җитәкчесе Владимир Чагин ТАССта узган очрашуда.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ПИНОЧЕТ ТАРАФДАРЛАРЫ ҖИҢЕЛДЕ

Үткән атна планета күләмендәге давыллы-ярсулы, тарихи вакыйгаларга, истәлекле даталарга бай булды. Вазгыятьнең төп этәргече ролен «омикрон» штаммы үз өстенә алды шикелле. Иң нык вакциналанган һәм чит илдән килүчеләрне һәрвакытта да инә күзеннән үткәргән кебек тикшереп кертүче ил – Израильнең Премьер-министры Нафтали Беннет матбугат конференциясе җыеп: «Израиль барыннан да алда чикләрне бикләп, кыйммәтле вакытны отты, әмма «сатып алган вакыт» бетеп килә, «омикрон» инде илдә, хәрәкәт итәргә кирәк», – дип белдерү ясады. Ул, бишенче дулкын башланды, дип игълан итте (бездә әле өченче дулкын гына бетеп килүен искә алсак, бар көченә саклanучы илнең бездән ике дулкынга алда баруы гаҗәпләндерә, билгеле), мөмкин булган бар кешене дә өйдә эшләргә җибәрергә әмер бирде, ашыгыч рәвештә балаларга вакцина ясатырга өндәде. Илнең Сәламәтлек саклау министрлыгы чирләгән өч кешенең берсе инде «омикрон»лы булуы турында рәсми белдерү ясады. Чир индексы үсә, Кнессетның (ил парламенты) 9 депутаты карантинда утыра.

Европада да – «омикрон» өянәге. Нидерландта кырыс локдаун. Азык-төлек кибетләреннән кала барлык кибетләр ябылды. Кешеләрне өйдән чыкмаска өндиләр. Германия һәм Италия яңа чикләүләр турында уйлый. Италиядә тулысынча вакциналанган кешеләрдән дә җәмәгать урыннарына бару өчен тест тапшыруны таләп итәләр, битлекне урамда да салмау мәҗбүригә әйләнде. Лондон мэры Садик Хан башкалада гадәттән тыш хәл игълан итте. Америка матбугаты госпитальләрнең тулы булуы хакында яза.

17 декабрьдә «гарәп язы»н этеп җибәргән вакыйга – Туниста Мөхәммәт Буазизиның полиция башбаштаклыгына протест белдереп үз-үзен ут төртеп яндыруына 11 ел булды. Шул үлемнән башланып, Төньяк Африка һәм Якын Көнчыгыш илләрендә дулаган фетнә бүген бар дөньяны чолгап алды. Үткән шимбәдән якшәмбегә каршы төндә урам гыйсъянчылары Бөекбритания Премьеры Джонсон резиденциясен чолгап алдылар һәм аздан гына бәреп керми калдылар. Барлык Европа шәһәрләрендә дә киеренкелек дәвам итә.

Ерак Латин Америкасындагы Чилида ике мөһим вакыйга булды. Үткән гасырның җитмешенче еллары башыннан туксанынчы елга кадәр ил белән идарә иткән канлы диктатор Пиночетның хатыны Люсия Хириарт йөзенче яше белән барганда вафат булды. Аның үлемен Сантьягода яшәүчеләр «Пиночет династиясенең тәгәлләнүе» дип урамнарга чыгып бәйрәм иттеләр. Илдә Президент сайлавы да булып узды. Анда көрәш Пиночет тарафдары белән аның тарафыннан бәреп төшерелгән һәм үтерелгән Сальвадор Альенде варисы арасында барды. Сайлауда үтә сул кандидат Габриэль Борич җиңеп чыкты. Чили халкы яңадан коммунизм тарафына борылыш ясарга тели. Сул идеяләрнең популярлашуы дөньяның башка почмакларында да күзәтелә.

Россиядә

БЕЗДӘ ИКЪТИСАД МӨҺИМРӘК

Россиядә әлегә «омикрон» тәэсире сизелми диярлек. Барлык симптомнары да традицион ОРВИны хәтерләткән бу чир, күрәсең, бер-ике айдан соң мәйданга чыгар. Күп кенә вирусологлар аны пандемиянең тәгәлләнүенә – соңгы аккордына юрыйлар. Без дә шулай булыр дип өметләник. Әлегә Мәскәү өчен НАТО блогы белән конфронтация һәм икътисад проблемалары мөһимрәк. Россиянең Тышкы эшләр министрлыгы Брюссельгә берничә кискен пункттан торган ультиматум юллады. Төп таләп – НАТОның 1997 елгы чикләргә әйләнеп кайтуы. Көнбатышның хәрби блогы бу таләпкә буйсынып дип уйларга ярамый, димәк, киеренкелек үсүдән туктамастыр, мөгаен.

Үткән җомгада Үзәк Банк төп ставканы 8,5 процентка кадәр күтәрде. Бездә рәсми инфляция дәрәҗәсе шул чама дип бәяләнә бит инде. Кредитларның кыйммәтләнүеннән бизнес бер дә канәгать түгел. Нәбиуллина конторасы процентны күтәрү юлы белән инфляция камырын кире савытка этеп кертәбез дип вәгъдә бирә һәм киләчәктә дә шул юнәлешне тотарга ниятли.

Инфляция дигәннән, илнең төп матбугаты – «Российская газета» дүшәмбе санында ни өчен бәяләр 1,5–3 тапкыр артканда, инфляция күрсәткече 8 процент кына дигән сорауга җавап бирергә тырышты. «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе ул язмадан төп сорауга җавап тапмады никтер, бәяләрнең күтәрелү сәбәпләренең барыбызга да мәгълүм булган бәянын генә укыды. Төп финанс хакимиятләре процент ставкасын күтәргәч, бәяләр яңадан элекке эзгә кайтыр дип вәгъдә бирәләр. Түбә калаеның бәясе төшүен мисал итеп китерәләр. Чынлап та, көзге якта металл чирәп бәясе төште, әмма бу башка товарлар өчен кагыйдәгә әйләнмәде әлегә.

Финанс министры Антон Силуанов 2022 елда икътисадта ыргылыш булачак дип вәгъдә бирә. Андый вәгъдә ел саен бирелә ул үзе. Быелгысы, бәлки, могҗиза булып, тормышка ашмасмы. Әлбәттә, Үзәк Банк төп ставканы мондый темплар белән үстерсә, кредит алып нәфесен канәгатьләндерүчеләр саны кимер, товарларга ашкынулы ихтыяҗ тукталыр, шул сәбәпле вакытлыча булса да бәяләр дә тормозга басар, мөгаен. Үзәк Банкта вакыйгаларның нәкъ менә шундый үсешенә өметләнәләр дә. Әмма вазгыять бер Россия базарындагы атмосфера белән генә билгеләнми бит. «Кара алтын»га бәяләр ничек торыр, Көнбатыш илләрендәге яңа башланып килүче кырыс локдауннар икътисадка нинди тәэсир ясар, санкцияләр белән ничек кыланырлар – боларның берсен дә без алдан белмибез. АКШ Федераль резерв системасы нинди карар кабул итүгә кадәр бәйле безнең кесәләрнең хәле. Локдаун дигәне дә безгә килеп җитми калмас инде аның.

Европада яңа катастрофа – киберһөҗүмнәр нәтиҗәсендә ут өзелү белән куркытучы сәясәтчеләр саны арта. Димәк, аренага «кибersугыш» дигән яңа дәһшәт чыгуы ихтимал. «Омикрон» һөҗүмен, Аллаһ теләсә, уздырырбыз, менә бу соңгысы булмасын иде инде аның.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

КИЛӘЧӘК ӨЧЕН КЕРТЕМ

Президенттан – хәер-фатыйха. Рөстәм Миңнеханов Түбән Камадагы «Танеко» заводында тантаналы төстә өч яңа җитештерү җайланмалары комплексын эшләтеп җибәрде. Болары – әлегә сынау рәвешендә.

tatarstan.ru

Яңа җайланма нефть эшкәртү тирәнлеген һәм ачык төстәге нефть чималы чыгуын арттырачак. Шул рәвешле «Танеко» нефть продуктлары ассортиментын киңәйтәчәк.

Чарада катнашкан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бу җайланмаларның компания һәм тармак өчен әһәмиятле булуын ассызыклады.

– Быел 4 яңа җайланма эшләтеп җибәрдек. Тагын өчесен сынап карыйбыз. Бу – 39 млрд сум күләмендәге инвестицияләр. «Татнефть» компаниясе һәм аның генераль директоры Наил Мәгановка рәхмәт. Алар бу комплекс өчен беренче казык кагылган көннән бирле тырыша. Бүген инде нәтиҗәсен күрәбез, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Комплекс төзелеше тармак үсеше өчен этәргеч бирде, «Танеко» тәҗрибәсен ил күләмендә һәм читтәге башка объектларда да кулланырга була. Хезмәтегез өчен рәхмәт әйтәм. Сезнең уңыш – республикабыз муллыгы ул.

Моннан тыш Президент катнашында «Танеко»ның 2021 елдагы нәтиҗәләренә багышланган утырыш узды. Искәртеп китик: быел предприятие өчен юбилей елы булды – 10 ел элек ул сәнәгать эксплуатациясенә керде.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, дистә ел эшчәнлек дәверендә «Танеко» 90 млн тоннадан артык нефть чималы эшкәрткән. Завод төзелеше башланганнан бирле барлыгы 470 млрд сум күләмендә акча инвестицияләнгән. Татарстан Президенты «Танеко» хәзерге вакытта илдә иң яхшы нефть эшкәртү комплексы булып саналганын искәртте.

Бу көнне Рөстәм Миңнеханов Әлмәттә «Татнефть» компаниясе утырышында да катнашты. Директорлар советы вәкилләре 2021 елның 11 аенда бюджет үтәлеше турында хисап тотты һәм 2022 елның беренче кварталына бюджетны раслады.

Утырышта компаниянең башка әһәмиятле эшләре турында да сүз булды. Әйтик, «Татнефть» Россиядән читтә нефть-газ чыгару, геологик тикшерүләр өлкәсендәге проектларны тормышка ашыра. Аерым алганда, компания Ливиядә геологик тикшерүләрне яңадан башлап җибәргән. Биредә «Татнефть»нең 4 килешүе бар.

Төрекмәнстанда «Татнефть» «Төрекмәннефть» компаниясе белән хезмәттәшлек килешүен гамәлгә ашыра, шуның нәтиҗәсендә өстәмә табыш 400 мең тоннадан артты, 200 геологик-техник чара үтәлгән, электр насослары һәм насос-компрессор торбалар җайланмаларын төзекләндерү эшләре оештырылган.

Моннан тыш утырышта катнашучылар 2022 елга «Тикшерү һәм табыш» бизнес-юнәлешенең фаразлары белән дә таныштылар. Директорлар советы, тышкы сәбәпләрне һәм ОПЕК+ карарларын исәпкә алып, килеп туган бурычларны хәл итү турында карар кабул итте.

Президент Рөстәм Миңнеханов һәм Россиянең спорт министры Олег Матыцин видеоэлемтә аша республиканың биш районында ябык футбол манежларын ачуда катнашты. Әлмәт, Бөгелмә, Зәй, Чистай һәм Әгерҗедә урнашкан спорт объектлары республика программасы һәм башка чыганаклар ярдәмендә төзелгән.

«Бездә футбол белән 50 меңгә якын кеше шөгыльләнә. Мондый инфраструктура булганда бу сан икеләтә, өчләтә арттырга да мөмкин, мин моңа ышанам. Әлеге спорт объектлары футболны һәм сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга ярдәм итәчәк», – диде Татарстан Президенты. Рөстәм Миңнеханов республикада спортны үстерүгә ярдәм иткән предприятиеләргә рәхмәт әйтте.

Олег Матыцин да Татарстанның дәүләт белән бизнес арасындагы хезмәттәшлекнең уңай үрнәген күрсәтүен әйтте. «Без бу тәҗрибәне башка төбәкләргә дә кулланырга тәкъдим итәбез. Хәзерге катлаулы заманда мондый хезмәттәшлек бик мөһим. Ул, беренче чиратта, спорт белән шөгыльләнү өчен мөмкин кадәр уңайлы шартлар булдыруга, шулай ук спорт корылмаларының ачык булып, кешеләрнең аннан файдалана алуына юнәлтелгән», – диде ул.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсе проектлаштыру хезмәтенең проектларга экспертиза уздыру төркеме әйдәүче инженеры **Минеджян** Венера Шамил кызы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: генераль директорның техник тәэминат һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәте комплексы үзәк лабораториясе башлыгы **Гыймадиева** Резедә Рәшит кызына, генераль директорның техник тәэминат һәм сыйфат буенча урынбасары **Зурбашев** Алексей Владимировичка, генераль директорның техник тәэминат һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәте комплексы үзәк лабораториясенең сыйфатка контроль лабораториясе әйдәүче инженер-химигы **Латыйпова** Эльмира Илгизәр кызына, нефть эшкәртү заводының товарлыклы-чимал производствосы керосин һәм реактив ягулык товарлыклы резервуар паркы участогының товар операторы **Шакиров** Рафаэль Марс улына **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәте электр җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү хезмәтенең нефть продуктлары өчен резервуар парклар электр җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны төзекләндерү участогы электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Юнысов** Госман Әбелгата улына **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенең хуҗалык идарәсе аучылык хуҗалыгы директоры **Зорин** Валерий Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган экологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының егерме сигезенче утырышы 24 декабрь көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Дәүләт Советы депутатларын теркәү Дәүләт Советы бинасында 24 декабрьдә 8.00 сәгатьтә башлана.

КАЙНАР ЙӨРӘКЛЕ ИЗГЕ КЕШЕЛӘР

Безнең заман геройлары

Казанда «Безнең заман геройлары» республика иҗтимагый премиясе лауреатларын бүләкләделәр. Әлеге проект кысасында гадәти тормышта чын каһарманнарча гамәл кылучылар хөрмәтләнә. Татарстан һәм Идел буе федераль округының башка төбәкләреннән яшь геройларны республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

– Көндәлек тормышта батырлыкка һәрвакыт урын бар, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Кемдер, кешеләрне коткару өчен, ике дә уйлап тормастан, янып торган өйгә ташланган, кемдер ялгыз картны гаиләсенә тәрбиягә алган, ә кемнәрдер үзендә каты авыруны җиңүгә көч табып, тормышын яңа биттән башлап җибәрә алган.

Парламент башлыгы әйтүенчә, «Безнең заман геройлары» – гадәттән тыш хәл килеп чыкканда фидакарьлек һәм кыюлык үрнәге күрсәтеп, кешеләрне үлем тырнагыннан йолып калуга ирешкән эчкерсез кешеләр. Арада һөнәренә бәйле рәвештә һәр көн саен чын батырлык кылучылар да бар. Намус һәм вөҗдан аларга башкача эшләү мөмкинлеге бирми…

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, яшь геройлар үзләре генә түгел, бәлки аларны тәрбияләүче, кеше язмышына битараф калмаска өйрәтүче ата-аналары да бүләккә лаек. «Без республика киләчәге өчен лаеклы буын үстерәбез», – дип йомгак ясады парламент башлыгы.



tatarstan.ru

– Мондый геройлар аз түгел, әмма аларны киң җәмәгатьчелек белеп бетермәскә дә мөмкин, – дигән фикердә Фәрит Мөхәммәтшин. – Шуңа без мондый кешеләрне күрсәтергә, алар турында сөйләргә булдык. Болай эшләгәндә, аларның батырлыгы калган барча кеше өчен үрнәккә әйләнәчәк.

«Безнең заман герое» иҗтимагый премиясе, 2013 елдан бирле, һәр ел саен үткәрелә. Проектны Татарстан Президенты хуплаган. Шуңа күрә аңа 2016 елда республика статусы бирелгән. Соңгы дүрт ел эчендә Татарстаннан 76 кеше премия лауреатларына әйләнгән. 2019 елда премия форматы киңәйтелгән. Хәзер аның кысасында нәни геройлар форумы да уздырыла.

Быел 26 зур кеше һәм 15 бала «Безнең заман герое» һәм «Яшь герой» күкрәк билгеләре белән бүләкләнде. Фәрит Мөхәммәтшин Саратов өлкәсеннән 12 яшьлек Алексей Афанаскога, 15 яшьлек Данир Мөхәммәдиевкә (Башкортстан), 13 яшьлек Ансар Нурушевка (Самара) һәм Әлмәт шәһәреннән 13 яшьлек Алан Утяшевка шундый билгеләр тапшырды.

Алексей Афанаско бакча ширкәтендә сугару өчен булдырылган сулыкка кереп баткан 9 яшьлек баланы коткарган. Яшь герой малайның сулыкка егылуын күреп, аны ярга тартып чыгарган.

Данир Мөхәммәдиев исә бабасына кунакка кайткан җиреннән кечкенә малайның гомерен саклап калган. Данир сабыйны Кизил елгасыннан тартып чыгарган.

Ансар Нурушев Кутулук елгасында бозда шуганда суга төшеп киткән малайны үлем тырнагыннан йолып калган.

Быелгы геройлар арасында Әлмәт районыннан ике каһарман – Алан Утяшев һәм Ленар Дәүләтшин. Алан Әлмәт паркында дуслары белән уйнаганда, койма ава башлагач, дустын читкә этеп җибәргән һәм үзе шуның астында калган. Ленар Алабугада Шишкин буасында су коенган чагында аздан гына батмаган апалы-сеңелле ике кызны коткарган. Түбән Кама районыннан 16 яшьлек Илья Матюшенцев, йортта янгын чыгуын күреп алып, хуҗаларын уяткан һәм янгынны сүндерергә ярдәм иткән.

– Барлык каһарманнарыбызны кайнар йөрәккә ия булу, кешегә һәрвакыт ярдәм кулы сузу теләге берләштерә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Сез үз мисалыгызда игелеклелек, фидакарьлек һәм батырлык төшенчәләре мәгънәсенең беркайчан да югалмаячагын, бөек Ватаныбызның ышанычлы терәге булып хезмәт итәчәген күрсәтәсез.

БУРЫЧЛАРНЫ ХАЛЫК САЙЛАДЫ

Инде дүрт ел рәттән республиканың халыкка иң якын торучы алты министрлыгы – Сәламәтлек саклау, Мәдәният, Мәгариф һәм фән, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, Спорт, Яшьләр эшләре министрлыклары бурычлары халыкның тавыш бирү нәтиҗәләре буенча сайлап алына. Менә хәзер төп бурычлар исемлеге тулысынча әзер. Аңа һәр министрлык өчен 5–7шәр өстенлекле юнәлеш кергән. 2022 елда хакимият органнары алдына барлыгы 37 максат һәм бурыч куелган.

Бигрәк тә мәгариф өлкәсендәге мәсьәләләр халыкта, шулай ук белгечләрдә зур кызыксыну тудырган. Кешеләр тәрбиягә күбрәк игътибар бирү, балаларны психик басымнан, җинаятьчел субкультуралар йогынтысыннан саклау чаралары өчен иң күп тавыш биргән. Шулай ук төп бурычлар исәбенә инклюзив белем бирү, балалар ялы, инвалид балаларга белем алу өчен махсус шартлар тудыру бурычлары исемлеккә эләккән.

Яшьләрне укудан буш вакытларында эшкә урнаштыру Яшьләр эшләре министрлыгының иң төп бурычына әйләнгән. Моннан тыш аның 2022 елга төп бурычлары арасында – үсмерләргә психологик ярдәм, интернет челтәрендә яшьләрнең аңын томалый торган күренешләргә киртә кую.

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының төп өстенлекле юнәлешләре итеп, гадәттәгечә, фәкыйрьлеккә каршы көрәш һәм мәшгульлеккә ярдәм итү алынган. Яңалыклар арасыннан – авылларда 65 яшьтән өлкәнрәкләр диспансеризация һәм медицина тикшерүләренә министрлык сатып алган машиналарда йөртеләчәк.

Сәламәтлек саклау министрлыгының төп игътибар үзәгендә, халык теләге буенча, яман шешләрне ничек тә алданрак ачыклау, йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан интегүче балаларны табиблар күзәтүенә алу эшен көчәйтү, фельдшер-акушерлык пунктларын үстерү булачак.

Мәдәният мәсьәләләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләре бик көчле фикер алышулар белән үрелеп барган. Мәдәният министрлыгы башта бары тик 20 мәктәптә генә акварель белән рәсем ясау дәресләрен, мастер-класслар кертүне оештырмакчы булган. Әмма халыкның бу мәсьәләгә зур кызыксыну күрсәтүеннән чыгып, 200 мәктәптә мондый дәресләр үткәрү турында карар кабул ителгән.

Спорт министрлыгына килсәк, 2022 елда кимендә 20 яңа спорт объектын ачу, 15тән артыграк спорт корылмасын төзекләндерү күздә тотыла. Моннан тыш тавыш бирү нәтиҗәләре буенча министрлыкның Иҗтимагый советы спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүче балалар һәм аларның ата-аналары өчен онлайн платформа булдыруны хуплаган.

«ТАТАР ҖЫРЫ»: ЕЛ ВАКЫЙГАСЫ

tmtv.tatar

Ел бетә, димәк, «Татар җыры» җитә. Быел эстрада фестивале бер кичтә ике елның җырлы нәтиҗәләрен тәкъдим итте. Мәгълүм сәбәпләр аркасында, 2020 елда концертны оештырмадылар. Артистлар өчен дә, тамашачы өчен дә тансык чара булды ул быел. Беренчеләре «барс»ларын кулга алды, тамашачы шоу карап хозурланды.

«Барс-медиа» оештырган чараларның берсендә татар дөньясында танылган шәхес: «Барс-медиа» булмаса, күпме артист сәхнәгә чыкмаган булыр иде», – дигән иде. Хак сүзләр. Бу юлы, оештыручылар әйтүенчә, иң-иңнәр генә сәхнә тотты. Болар – халык теленнән төшмәгән җырчылар һәм җырлар. Араларында, бәлки, әле танылып ук җитмәгәннәре дә бардыр, концертта аларны да күрдек, ишеттек. Истә калдырып булырмы – анысы башка мәсьәлә. Сүз уңаеннан, «Татар җыры» 22 еллык тарихы дәверендә 1250ләп җыр һәм 500ләп лауреатны тәкъдим иткән.

Эч пошканга җыр файда, ди халык. Соңгы елларда кешенең болай да төшенкелек чигендә яшәгән чагы. Ярый әле концертлар бар: җыр белән булса да онытылырга, ял итәргә мөмкин. Концертның шәһәр читендәге «Казан Экспо»да узуы да (3 мең кеше сыйдырышлы залда!), билет бәясенең бик үк арзан булмавы да куркытмаган халыкны. Әйтик, Ләйсән Харисованың бу концертка тәүге тапкыр килүе икән. Гаҗәпләндерде, шаккатырды, ди. «Сәхнә – искиткеч, барысы да заманча. Концертны беренче номерыннан ук хисләнеп карадык. Ныклап әзерләнгәннәре сизелә. Кайбер концертларда йә тавыш ишетелми, йә җырчысы күренми, йә артык көчле тавыштан арасың. Биредә исә бөтен нәрсә үз урынында. Сәхнә тоткан җырчылар – минем балачактагы һәм яшьлегемдәге артистлар. Салават, Зөлфәт, Айдар абыйларны тыңлап үстек без. Концерттан соң да әле озак вакыт йоклый алмадык, җырчыларның башка җырларын тыңлап чыктык», – дип кичерешләре белән уртаклашты ул икенче көнне.

Концертта 30лап җырчы чыгыш ясаса да, алар белән күрешеп, хис-кичерешләрен сорашырга рөхсәт итмәделәр. Борчылганнардыр инде, аңлашыла. Алгы рәттә җәмәгате белән Татарстан Президенты да утырды бит, «Татар җыры»на җыелган халык та гомер-гомергә иркә иде – җырлы имтиханның нинди җитди булуын шуннан да чамаларга мөмкин. Үз тавышларына җырлаганнар сынатмады кебек. Иң истә калган чыгышлар Эльмира Кәлимуллина, Сәйдә Мөхәммәтҗанова белән Илнар Шәрәфетдинов, Динә Гарипова (Эльмира һәм Сәйдә белән трио да башкардылар. – **Ред.**), Гүзәл Уразова, Айдар Галимов, Ришат Төхвәтуллинныкы булгандыр.

Ә иң тансык кеше Зөлфәт Хәким иде. Чынлап та, әдәбият һәм мәдәният кырыннан югалып торган шәхесне күрү күпләр өчен концертның төп ачышы булды. «Ярты ел дәвамында Германиядә дәваландым. «Татар җыры» – минем өчен кадерле чара ул. Мин – аның беренчесенә сценарий язган кеше. Концерт Камал театрында узган иде. Җырларны мин тәнкыйть күзлегеннән карыйм. Җыр ул җитәкчегә дә, гади халыкка да кирәк. Аны дөрес кулланырга иде. Яшь буын чит-ят мохиткә тайпылмасын өчен мондый чаралар даими булып торырга тиеш. Мондый вакыйгаларның хәзерге вакытта булуы бик зарур һәм зур әһәмияткә ия, чөнки татар җыр сәнгате безне бергә җыеп, укмаштырып тора шикелле. Безне, татар халкын, милләт, бер кавем буларак берләштерә торган әйберләр күп түгел бит», – диде ул.

Журналистлар белән Башкортстанның атказанган артисты Элвин Грей аралашты. Сүз уңаеннан, аңа 2019 елгы «барс»ын тапшырдылар. Бүләкне соңарып алуына да «теге чир» гаепле. «Барысыннан да алданрак – 2019 елда авырып алдым мин. Шөкер, хәзер барысы да яхшы. Мине хөрмәт иткән тамашачыга рәхмәт. Иң төп теләк – авырмагыз. Бәхетле яшәгез. Бу ел коронавирус һәм пандемия белән истә калды. Артист өчен тагын ничек истә калсын инде? Заллар яртылаш кына тулы иде. 2022 ел җиңелрәк булыр дип өметләнәм. Барыбыз да прививкалы бит», – дип хисләнде Элвин-Радик. Өйләнү килешкән егеткә: басынкы ул хәзер. Сәхнәдә дә элеккечә итеп халыкны дәррәү куптара алмады. Радик лирик юнәлешкә күчмәгәе әле тиздән.

«Барс»лы булгач, үзе белән аерым сөйләшкән вакытта, Татарстан буенча гастрольләре турында кызыксындык. Хәтерләсәгез, узып баручы елда җырчының Роспотребнадзор белән аңлашылмаучанлыклары килеп чыккан иде. «Әлбәттә, концертлар булачак! Ник булмаганын беләсез бит? Роспотребнадзор рөхсәт итмәде. Мин аларга: «Ярар, бер ел вакытымны яңа җырларга, яңа программа әзерләүгә багышлыйм», – дидем. Татарстан буенча киләсе елның февраль, март айларына концертлар тәгаенләнгән инде. Исемлек тиздән әзер булачак», – дип уртаклашты Элвин Грей.

Хәзер инде концертның үзе турында бер-ике сүз. Шәп шоу булды ул. Күпме көч-хезмәт куелганын бер үзләре генә беләдер. Шулай да сценарийга бәйләнәсе килә. Продюсерлык культурасы, акрынлап булса да, татар эстрадасына тамыр җибәрә башлады инде бездә. Әллә соң хәзер мондый зур чараларга сценарий язучы үзәкләр булдырырга вакыт җиттеме? Югыйсә сәхнәдән теләсә нәрсә сөйләгәннәренә күнегә, ә иң кызганычы, моны кабул итә башлаячакбыз бит. «Татар җыры»нда урынсыз, кем әйтмешли, тозсыз сүз куертулар булмады түгел. Аерым шәхесләргә кагылулар (Элвин Грей белән Фирдүс Тямаев низагы, Ильмира Нәгыймова белән Руслан Кираметдиновның аерылышуы), антисептик эчмәскә киңәш, вакцина, QR-код системасы, эстрада вәкилләренә кушамат тагулар… Зәвыклы чараның зәвыксыз бер импровизациясе генә булгандыр дигән өметтә каласы килә.

Чараның икенче өлешендә чыгыш ясаган Гүзәл Уразова: «Минем хыялым – 20 елдан соң шушы фестивальгә сезнең оныклар килсен иде дә, миңа алар өчен җырларга язсын иде. Тормыш ничек кенә катлаулы булмасын, көчле булырга кирәк», – дип хисләнде. Халык килеште бугай. 20 елдан соң татар җырын тыңларлык буынны тәрбияләүне бүгеннән башларга кирәк икәнен дә аңлагандыр, шәт.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ИЛКҮЛӘМ «ЕЛ СТУДЕНТЫ – 2021» ҖИҢҮЧЕСЕ:

«КӨЧНЕ ДӨРЕС ЯККА ЮНӘЛТӘ БЕЛЕРГӘ КИРӘК»

Россиянең иң шәп студенты – нинди ул? Моны Илкүләм «Ел студенты – 2021» премиясендә һөнәри белем бирү оешмаларында укучы студентлар арасында төп бүләк – гран-прига ия булган Алия Әһлиуллина яхшы белә. Алия киләчәккә нинди планнар кора? Бүген студентларны нәрсә борчый? Без әнә шул хакта сөйләштек.

«Тумышым белән Нурлаттан мин. Мәктәптә укыган чакта бию түгәрәгенә йөрдем, волонтерлык белән шөгыльләндем, белем йортыбыздагы укучылар үзидарәсенең бер вәкиле идем. Мәктәпне «бишле» билгеләренә генә тәмамлап, Россия дәүләт гадел хөкем университетының Казандагы көллиятенә укырга кердем. Бүген минә өченче курста белем алам», – дип таныштырды Алия үзе белән.

Укудан тыш җәмәгать эшчәнлеге белән дә шөгыльләнә ул. Студентлар берлегенең беренче курста белем алучылар белән шөгыльләнүче махсус комитетында «Кураторлар һәм остазлар мәктәбе» җитәкчесенең урынбасары булып тора. Моннан тыш, республика күләмендә уздырылучы «Беренче лига», «LIGA PROF», «LIGA FORUM», «Ел казанышы» һәм башка проектларда актив катнаша, шушы ук чараларда оештыручы буларак та читтә калмый. «Студентлар тормышының минә шул яклары ошый да инде. Моны мин икенче курста укыган чакта аңладым. Укып кына утыру күңелсез бит, яшь чакта ташып торган көчне дөрес якка юнәлтә белергә кирәк! Әлбәттә, укудан тыш эшчәнлегем күп вакытымны алса да, беренче чиратта мин – студент. Актив тормыш рәвеше алып бару чыныктыра, тагын да күбрәк эшләргә этәрә, вакытны дөрес бүләргә өйрәтә. Шуңа күрә укуда авырлыклар туганы юк», – ди Алия.

Аның белән без студентларны борчыган мәсьәләләр турында да сөйләштек. «Кайсы гына чорны алсаң да, студентларны һәрвакыт йокысызлык, сессия, акча җитмәү борчыган. Еллар узу белән әлеге мәсьәләләрне хәл итү юллары гына үзгәрә. Бүген студентларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максаты белән төрледән-төрле иҗтимагый оешмалар эшли. Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгы ел саен яңа грант проектлары белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен тиешле ярдәм күрсәтә. Һәркайсын исәпкә алсаң, мөмкинлекләрнең күп булуы күренә», – дип сөйләде ул.

Илкүләм масштабтагы «Ел студенты» премиясендә Алия тәүге тапкыр катнаша икән. «Быел мин «Ел казанышы» республика премиясендә катнаштым. Әлеге чара миңа бик күп яңа мөмкинлекләр ачты, үземнең көчемә ышанырга ярдәм итте. Моннан тыш, «Ел казанышы»ндагы көндәшләремнең файдалы күнекмәләрен дә үзләштердем. Миңа калса, Россия күләмендә үз эшчәнлегемне лаеклы дәрәҗәдә тәкъдим итәргә нәкъ әлеге бәйге ярдәм итте», – дип сөйләде Алия.

«Премиягә ничек әзерләндегез соң?» – дип тә сорадык без аннан. «Ел студенты» премиясенә мин «Ел старостасы» номинациясенә гариза бирдем. Читтән торып катнашу этабын узганнан соң мине дистанцион форматта узачак төп этап көтә иде. Анда без барлыгы дүрт төрле сынауда көч алыштык. Аларга без бик нык әзерләндек. Республика премиясендә тәкъдим ителгән барлык уңышлы презентацияләрне яңадан карап, үз эшчәнлегемне анализлап, нәрсәгә басым ясарга кирәклеген чамаладым. Дусларым, студентлар берлеге һәм җитәкчеләр алдында чыгыш ясап карадым. Сынаулар вакытында, кара-каршы утырып аралашмасак та, Россиянең төрле төбәкләреннән булган катнашучыларны тыңлау һәм тәҗрибә белән уртаклашу аеруча кызык булды. Ә инде җиңүем турында ишеткәч… Ышанмадым! Бу турыда хыяллана гына идем. Бу урында минем гаиләмә, безнең уку йортында тәрбия бүлеге җитәкчесе Юлия Гариповага һәм әлеге бүлекнең барлык хезмәткәрләренә, Татарстан делегациясе җитәкчесе Нелля Пулатовага, шулай ук остазларым Алия Кыямова һәм Никита Лобановка аерым рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә», – дип сөйләде ул.

Алиянең киләчәккә планнары зурдан. «Яңа исем – яңа мөмкинлекләр. Алардан булдыра алганча файдаланасы иде. Ниятләр инде билгеләнгән, тормышка ашырасы калды. Алда мине соңгы курс, диплом эшен яклау, югары уку йортына укырга керү һәм студентлар тормышы белән бәйле бик күп яңа проектлар көтә. Сез алар турында һичшиксез ишетерсез әле».

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Кайсыгызның кулы җылы?

Энҗе бөртекләре

Бу бәйгедә җиңелүчеләр юк. Мөмкинлеге чикле хатын-кызлар арасында узучы «Татарстан энҗесе» VIII республика бәйгесендә катнашучылар турында шулай диләр.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

– Сигез ел элек Гөлнара Заһретдинова минем янга килеп, мөмкинлеге чикле хатын-кызлар арасында бәйге уздырырга иде, дигәч, катнашучы булырмы, дип шикләнгән идем. Сез бу чараның кирәклеген расладыгыз, – диде бәйгенең жюри рәисе, Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова катнашучыларга. – Бу бәйгедә бик күп кызлар катнашты. Сайлый башлагач, аларның араларыннан берсен генә аерып әйтү авыр. Әлеге гүзәл затларга сокланмый мөмкин түгел. Сез бәхеткә лаек. Гел бәхетле булыгыз.

Һәр катнашучы кыз төрле номинацияләрдә җиңүче булды. «Татарстан энҗесе» исеменә Әлмәт районының Ак чишмә авылы кызы Тамара Осина лаек дип табылды. Җиңгәненә ышанып бетә алмый Тамара. «Мине бу бәйгегә әзерләгән һәркемгә рәхмәтлемен», – ди ул.

«Татарстан энҗесе»ндә икенче булган Миләүшә Петрова исә Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипованың ярдәмчесе итеп билгеләнде. Ул бер ел буе физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрнең проблемаларын хәл итүгә үз өлешен кертергә тырышачак.

Әлеге бәйгене моннан сигез ел элек апалы-сеңелле Гөлнара һәм Гөлназ Заһретдиновалар башлап җибәргән иде. Бүген Гөлнара бу эшне үзе генә алып бара. Сеңлесе Гөлназ кияүдә, тиздән әни булырга җыена. Гөлнара исә бәйге уздырыр өчен төрле грантлар ота, бәйгеләрдә җиңә. Аның инде үз командасы бар. Иганәчеләр дә ярдәм итә.

Бу чарада бәйгедә катнашучыларны гына түгел, Гөлнараның үзен дә тәбрикләделәр. Ул бик күп рәхмәт сүзләре ишетте. Физик мөмкинлекләре чикләнгән кызларга юл күрсәтүче, аларны дөньяга алып чыгучы бит.

– Кемнедер сөендерә алуыма шатмын, – ди ул. – 8 ел элек сеңлем белән Европага баргач, андагы физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрне күреп шаккаттык. Анда бөтенләй башка караш. Кайттык та, бездәге кызлар өчен берәр бәйрәм ясыйсы килде. Ул чакта минем ательем бар иде. Кызларга киемнәр тегеп, мода күрсәттердек. Аннан соң аларны матур итеп бизәндердек. Бик шатландылар. Безнең бу чараны күргән кешеләр, моны киләчәктә дә дәвам итегез, диделәр. Хәер, катнашучы кызлар үзләре дә, бәйге кайчан була, дип сорап кына торалар.

Гөлнара әйтүенчә, хәйриячелек ул акча җыю, акча өләшү генә түгел. Ул – кемнедер сөендерә алу, күңелен күрү дә. Әнә бит бәйгедә катнашучы кызлар, янына килеп, бу көн – минем иң бәхетле көнем, дип әйтә икән. Ничек инде аларны бу бәхеттән мәхрүм итәсең?!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ИКЕ БАТЫРГА – БЕР МЕДАЛЬ

Көрәш

Казанда көрәш буенча елның соңгы зур бәйгесе узды. Федерация Кубогы өчен бил алышкан егетләргә бу юлы гадәттәгечә 10 түгел, ә нибары 5 категориягә бүленеп ярышырга туры килде. Шулай итеп, җиңүгә дәгъва кылучылар артты.

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

Марат ӘХМӘТОВ, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республиканың көрәш федерациясе җитәкчесе:
– Үз традициясен дәвам итеп, көрәш ел дәвамында барды. Календарьда каралган ярышлар барысы да диярлек үтәлде. Икенче яктан, тамашачыларны ярышка тарту проблемасы булды. Ә менә егетләрнең әзерлегендә, осталыгында бернинди торгынлык сизмәдем. Аларның көчле икәне күренеп тора. Көрәш елыннан гомумән канәгать. Бер генә теләк: безгә күбрәк тамашачыны тарту, көрәшнең массалыгын үстерү.

Көрәш федерациясе зур ярышлар башланырга бер көн кала берәр мәсьәлә турында утырып фикер алышу гадәтен кертте. Бу юлы допинг мәсьәләсендә сөйләшергә карар кылганнар. Ни өчен нәкъ менә допинг, ул-бу юктыр бит?

– Кисәтү өчен уздырдык. Кисәтелгән, димәк, коралланган дигән сүз бар бит. Безнең көрәшчеләр Россия, дөнья чемпионатларында чыгыш ясый. Барысы да белеп торсын. Табиб аңлатып сөйләде. Һәр нәрсәнең үз тәртибе бар, – диде көрәш федерациясенең башкарма директоры Марсель Таһиров, шикне тамырыннан корытырга тырышып. – Бездә допинг проблемасы бар дип уйламыйм. Мин көрәшкән вакытларда бу хакта ишеткән дә юк иде.

Карыйм-карыйм, һич таба алмыйм

Ә менә ярыштан соң көрәш җәмәгатьчелегенең ни хакында сөйләшәсен фаразлавы кыен түгел. Темасы алдан ук билгеле: хөкемдарлар турында, әлбәттә. Монысы көрәштәге күптәнге гореф-гадәт инде. Бу урында федерациянең келәмдәге гаделлек юнәлешендә зур гына бер адым ясаганын әйтү мантыйклы булыр. Бәйгеләрдән «Ютуб»тагы канал аша туры трансляция оештыра башладылар. Бер яктан, Казанга килеп көрәш карый алмаган тамашачыга җайлы. Икенче яктан, теге яки бу очрашуны кабат-кабат карарга мөмкин. Әлбәттә инде, бәхәсле мизгелләрне һәркем үзе аңлаганча һәм үзе теләгәнчә күрә. Федерация җитәкчесе, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтовның исә хөкемдарларга киңәше дә бар.

– Аларның тамашачы күзлегеннән дә караулары кирәк. Әйтик, ике көчле егет бил алыша. Берсе тырыша, әмма алымны эшләп бетерә алмый. Аркасына төшәргә мәҗбүр. Көндәше аны төртеп, аркасына яткырырга дип күтәп кенә тора, – ди ул. – Артык кырыс булмасалар да ярар иде. Чөнки тамашачының үзенең дә бик көчле көрәшчеләрнең бил алышуын озаграк күрәсе килә. Бу бит гади авыл Сабан туендагы малайлар көрәше генә түгел. Һәр көрәшче көндәше белән кайчан һәм ничек очрашканын искә төшереп, анализ ясап бил алыша.

Федерация башкарма директоры Марсель Таһиров хөкемдарлардан канәгать. Аларның әзерлеген дә, эшен дә яхшы бәяли.

– Җиңелгән кеше барыбер канәгать булмыйча кайтып китә. Хәтта икенче урын булса да. Мин моны көрәшче буларак әйтәм. Димәк, бу ярыштан 5 кеше генә тулысынча канәгать калды. Нинди генә кагыйдә булсын, хәтта Америкадан хөкемдар китереп утыртсаң да, җиңелгәне канәгать булмаячак, – ди ул. – Икенче яктан, хөкемдарлар бит Кәлимуллинны берни эшләтә алмый. Безнең бәхәс һәм тавыш көрәшчеләр тигез бил алышканда чыга. Хөкемдарларга да җиңел түгел. Егетләр көчле һәм бер-берсен яхшы беләләр.

Раил көрәшәчәк әле

Көчле һәм бер-берсен белгән егетләргә бу юлы яңача бил алышырга туры килде. Юк, кагыйдә үзгәрмәде. Ярышны уздыру рәвешендә үзгәрешләр бар. Финалга барып җиткән батырларга оттырган көрәшчеләр «юану» ярышында чыгыш ясады. Төп вакыйга исә үлчәү категорияләрен ике мәртәбә киметеп, нибары 5кә калдыру булды. Шулай итеп, моңа кадәр рәсми ярышларда очрашу мөмкинлеге булмаган егетләрнең үзара көч сынашуын күрдек.

65 килолы егетләр финалында Актанышта туып-үскән ике егет очрашты. Раббани Нургалиев бу юлы үз районы данын якласа, Искәндәр Мортазин Әлмәт тамашачысын сөендерде. Җиңү көндәшләрнең яшьрәге – Раббанига тәтеде. 75 килолы көрәшчеләр ярышында Лаештан Динар Кәримуллин батыр калды. Тукай районыннан Илназ Рамазановка тәҗрибә җитмәде. Гадәттә көндәшләрен бер сулышта диярлек җиңеп чыгучы Ренас Кәлимуллинга бу юлы җиңел булмады. Моңарчы ул 80 килолы егетләр белән ярышты. Бу юлы 85 килолылар белән бил алышырга туры килде. Көндәш – әле 1 ай элек кенә 90 килолылар арасында көрәшеп, Татарстан Чемпионатында икенче булган Айрат Сәмигуллин. Кемнең җиңәсе ахырга кадәр билгеле түгел иде. Алыш Айратның өч кисәтү алып оттыруы белән тәмамланды.

Турнирның яңача уздырылуыннан иң зур файда күргән кеше Раил Нургалиев булгандыр, мөгаен. Соңгы вакытта үзеннән күпкә авыррак булган 130 килолы егетләр белән азапланган Теләче егете бу юлы 105ләр арасында ут уйнатты, финалда исә Башкортстан егете Айнур Сыртаевны чистага салды. Көрәшәчәк әле Раил! 130 килолы егетләр арасында исә Радик Сәлахов көндәшен чистага алып салды. Актаныш өчен бил алышкан Валерий Рәфыйков 28 секунд кына бил алышып калды. Аннары Раилнең үзен ыргыттылар, дөресрәге, һавага чөйделәр.

Командалар арасында бу юлы Әлмәт беренче булды. Кукмара икенче урынны алды, Теләче көрәшчеләре өченче була алганнарына сөенде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, ире
ЛАРИОНОВ Евгений Леонидовичның
гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, сигезенче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты, бишенче һәм алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ларионова Татьяна Петровнаның авыр кайгысын уртаклаша. Бу авыр көннәрдә сезгә сабырлык һәм ныклык бирсен.

«ТАТНЕФТЬ»НЕҢ ЯШЕЛ РЕКОРДЫ

КОМПАНИЯ ТАТАРСТАНДА МИЛЛИОНЛАГАН АГАЧ УТЫРТА

Экология

Республиканың яшеллеккә күмелүендә «Татнефть» компаниясенең өлеше гаять зур. Быел алар 8 миллион агач утырткан. Гомумән алганда, «Татнефть» ярдәме белән 2000–2020 елларда республикада 12 миллион төптән артык агач утыртылган. Алар яшеллеккә аеруча кытлык булган урыннарда, чокыр-чакырларда, ерымнарда үсә. Компаниянең урманнар утырту белән бәйле нинди проектлары бар? Биологик сыйныфларның үзенчәлеге нидә? Без шул хакта белештек.

Урманнарны торгызу

Яңа урманнар утырту – «Татнефть» компаниясе һәм республика Урман хуҗалыгы министрлыгының планлы зур эше. Ул БМОның Глобаль килешү кысаларында һаваның сыйфатын яхшырту һәм парник газларын чыгаруны киметү буенча проектның мөһим өлеше булып тора. Быел компаниянең хезмәт коллективлары конференциясендә чыгыш ясаганда «Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Наил Мәганов экологиягә игътибарны тагын да арттыру бурычы куелганлыгын искәрткән иде.

– Без агачлар утырту хисабына компенсацияләү чараларын киңәйтү бурычын куйдык. Экологиянең җитди мәсьәлә икәнлеген аңлыйбыз. Табигатьне торгызу, үз халәтенә кайтару – безнең гражданлык бурычыбыз, – диде ул.

Гомумән алганда, компания урманнар белән бәйле программаларга 2000 елдан бирле игътибар күрсәтә. Ә 2013 елдан ул «АЗСтан – урман» («Лес от АЗС») проектын эшләтеп җибәрде. Мәгълүм булганча, компаниянең ягулык салу станцияләреннән кергән акчаның бер өлеше яшеллек булдыру өчен тотыла. Урман экосистемасын торгызу исә үсемлекләр һәм хайваннарның санын, төрләрен арттырырга ярдәм итәчәк. Ә машиналар күп йөри торган трассалар янында утыртылган агачлар кешеләрне агулы газлардан һәм юллардагы тавыштан сакларга булышачак.

Быел компания «Циркуляр урман» дип аталган тагын бер зур проект башлап җибәрде. Проект нигезендә – усак агачы үсентеләре. Тик гади түгел, триплоид усак (ягъни өч хромосомалы гибрид) һәм ул клонлаштыру юлы белән үрчи. Ни өчен нәкъ менә усак соң? Чөнки, белгечләр әйтүенчә, әлеге агачлар, чыршы һәм нарат белән чагыштырганда, углерод диоксидын (углекислый газны) ике тапкырга күбрәк йота. Шулай ук алар башкаларга караганда тизрәк үсә һәм теләсә нинди һава шартларына яраклашырга сәләтле. Болар өстенә, усакның әлеге төре куе булып үсә һәм урманнарда дала үсемлекләре таралуга комачаулый.

Көн үсәсен төн үсә

Шунысы мөһим: әйләнә-тирә мохитне, табигатьне саклау эшенә «Татнефть» яшь буынны да җәлеп итә. Республиканың көньяк-көнчыгыш районнарында биологик сыйныфлар ачылу да шул максаттан. Уникаль сигез сыйныфның өчесе Азнакай районының Актүбә, Победа бистәләрендә һәм Мәлбагыш авылы мәктәбендә тупланган.

Мәлбагыш мәктәбенең биология һәм химия укытучысы, биологик сыйныф белән җитәкчелек итүче Зинаида Сәмигуллина сөйләвенчә, заманча җиһазландырылган лабораториядә эшләр өчен бөтен шартлар тудырылган.

– Узган елның августында «Татнефть» компаниясе безгә биологик сыйныф һәм шуңа янкорма итеп биологик лаборатория төзеп бирде. Төп эшләр шунда башкарыла. Һәркайда стериль чисталык булырга тиеш. Бу мәсьәләдә бер авырлык та юк. Кирәкле барлык приборлар, җиһазлар белән компания тәэмин итеп тора. Шул вакытта ук безгә клонланган үсемлекләр алып килделәр. Хәзер без әзер материалны микроклонлаштыру белән шөгыльләнәбез, – диде ул.

Лабораториядә укучылар усак, каен, ак сирень, кара бөрлегән, җиләк, чәчәк үсентеләре белән эшли. Шулай да төп игътибар усак агачына бирелә.

– Урманнарны торгызу максатыннан, агачларны төрләндерергә кирәк. Ә моның өчен озак вакыт таләп ителә, – ди Зинаида Сәмигуллина. – Мәсәлән, усакның чын агач булып җитлегүе өчен 25–30 ел вакыт кирәк. Ылыслы агачлар тагын да күбрәк вакыт сорый. Шуңа күрә компания усакның нәкъ менә триплоидлы төрен үстерергә булган. Алар тизрәк үсә һәм фотосинтез процессы өчен уңай шартлар тудыра. Димәк, бушап калган зур мәйдандагы җирләргә бу культураларны утырту безнең районда гына түгел, ә бөтен республикада атмосфера экологиясен яхшыртырга ярдәм итәчәк.

Үсентеләрне башта махсус боксларда үстерәләр. Аннары торфлы савытларга күчереп теплицаларга утырталар. Моңа кадәр аларны Әлмәткә җибәрә торган булганнар. Күптән түгел генә «Татнефть» мәктәпкә заманча, зур теплица урнаштырган. Хәзер үсентеләрне шунда күчереп утыртачаклар.

Укучылар – төп ярдәмчеләрем

– Бер елдан артык вакыт эчендә 19 меңгә якын үсенте үстердек. Әлегә үзебезнең теплицада 200ләп үсенте бар. Февральдә усакларны да шунда чыгарырга планлаштырабыз, – ди биология укытучысы.

Клонланган үсентеләрне укучылар, киләчәктә табигый тирәлеккә утыртып булсын өчен, стериль булмаган туфракка җайлаштыра. Мәсәлән, каен, ак сирень агачлары инде мәктәп ишегалдын матурлап утыра. Укучылар биологик сыйныфта да иң заманча җиһазлар кулланып, төрле тәҗрибәләр уздыра. Кыскасы, киләчәген химия, биология, медицина белән бәйләргә теләгән укучылар өчен мондый сыйныфлар – бик зур ярдәм.

Әлегә заманча җиһазландырылган лабораторияләрдә өлкән сыйныф укучылары шөгыльләнә. Ун егет һәм кыз «Киләчәкне булдыручылар» төркемен оештырган.

– Ят хезмәт булгач, башта авыррак булды, әлбәттә. Башлангыч вакытларда көн саен дәресләрдән соң шушы эш белән генә шөгыльләндек. Һәр үсемлеккә нинди тирәлек кирәклеген өйрәндек. Бер ел эчендә шактый тәҗрибә тупланды, үзебезгә күп яңалык ачтык. Укучыларым – минем төп ярдәмчеләрем, – ди 45 еллык хезмәт тәҗрибәсе булган укытучы. – Алар бөтенесен эшли. Үсентеләрне карый, тәрбияли, проектлар әзерли, конкурсларда катнашабыз. Шунысы куанычлы: «Татнефть» эшебезне, тырышуыбызны күрә. Һәркайсыбызга рәхмәт хатлары, премияләр тапшырды, укучылар «Татнефть» лагерендә ял итеп тә кайттылар.

Чыннан да, мәктәпнең биология, экология юнәлешендә уңышлары зур. Узган уку елында Мәлбагыш мәктәбе укучылары үзләренең проектлары белән республика конкурсларында призлы урыннарга лаек булган. Егет һәм кызларга хәтта халыкара форумнарда катнашу бәхете дә тәтегән.

«Татнефть» ярдәме белән республикада 12 миллион төптән артык агач утыртылган.

Инде бүгеннән үк өлкән сыйныф укучыларына акрынлап алмашчылар да әзерли башлаганнар.

– Биологик сыйныфларга түбәнрәк сыйныф укучыларын да җәлеп итә башладык. 5 нче сыйныф укучыларыннан башлап, теплицага алып керәбез, эш тәртибе белән таныштырабыз, – ди Зинаида Сәмигуллина.

Яңа проектлар

Хәер, укучылар да, тынгысыз укытучы да ирешкән уңышлары белән туктап калырга уйламый. Инде кабаттан яңа проектка алынганнар. «Сугыш балаларына канәфер чәчәкләре» дип аталган проектның максатын исеме үк ачып бирә.

– Мәлбагыш авылында әтиләрен бер тапкыр да күрмәгән 27 апа һәм абый бар. Теплицада канәфер чәчәкләрен үстереп, Бөек Җиңү көнендә аларны әлеге өлкәннәргә тапшырасыбыз килә. Чәчәкләрнең бик матур төрен сайладык. Җәй көне бакчага да күчереп була. Көзен-кышын гөл савытындагы чәчәкләр бүлмәне матурлыкка күмәчәк, – ди Зинаида ханым.

Моннан тыш, укучылар мискантус дип аталган яңа төр үсемлек белән дә таныша башлаган.

– Аларның биеклеге өч метрга кадәр җитә, – дип аңлатты укытучы. – Галимнәр әйтүенчә, киләчәктә әлеге үсемлекләрне күп максатларда куллану мөмкин булачак. Мискантус кәгазь җитештерүдә агачны алыштырырга сәләтле. Кыскасы, агачларны саклап калу һәм туфракны яңартуда әлеге үсемлекнең роле зур булачак. Галимнәр аны хәтта биоягулык буларак та файдалану мөмкин диләр. Хәзер без үсемлекнең үзлекләрен, үсү шартларын тикшерү, өйрәнү белән мәшгуль. Бер төрдәге 120 данәне урамга утырттык. Икенче төрен теплицага урнаштырдык. Алары анда тиз үсеп китте.

Ел башында биологик сыйныфлар эшчәнлеге белән танышып йөргән вакытта «Татнефть» компаниясе җитәкчесе Наил Мәганов укучылар үстергән агач үсентеләрен сатып алырга әзер булуларын әйткән иде. Мәлбагыш укучыларының исә сынатырга бер генә сәбәпләре дә юк.

Нәтиҗәдә «Татнефть» компаниясе утырткан агачлар республикадагы экологик вазгыятьне сизелерлек яхшыртыр дигән өмет бар. Шул ук вакытта Наил Мәганов: «Урманнар утырту гына аз. Әйләнә-тирә мохитне саклауда җаваплылык формалаштырырга кирәк. Бу табигать байлыкларын акыллы итеп файдалану, уңай экологик караш тәрбияләү, «яшел» башлангычларны арттыру дигәнне аңлата», – дип тә искәртте.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 386

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+